ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

**«10» ноябрь 2020 ел** **№ 877**

**2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогика, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы “Мәгариф турында” Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогика, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслауның нормативларын исәпләү турында Нигезләмәне раслау хакында” карарына һәм Арча муниципаль районы Уставына яраклаштырып, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән:

2021 елга Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогика, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә һәм балаларга өстәмә белем бирү

буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының  программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогика, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә расларга.

2. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесенә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын яңадан карауны өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә индексацияләү белән бер үк вакытта тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында  (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Т.Мөхәммәтшинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәррәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесенең
10 ноябрь 2020 ел, №877 карары
белән расланган

**2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотлык, социаль-педагогика, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше . | Территория ягыннан урнашуы | 1 укучыга елына норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче ел уку | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык һәм туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотлык | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогика | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |